| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ФЕДОТОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ФЕДОТОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

**2022 елның 1 июне** **№ 10**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 мартындагы 65-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 статьяны түбәндәге эчтәлекле унберенче яңа абзац белән тулыландырырга:
«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;
унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга;

23 статьяда:
13 абзацта «муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «,муниципаль гарантияләрдән килеп чыга» сүзләренә алмаштырырга;
19 абзацта «чагылдырылган муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «,чагылдырылган муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган.» сүзләренә алмаштырырга;
23 абзацны төшереп калдырырга;

27 статьяның 2 өлешендә «, һәм Җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен раслау» сүзләреннән соң «, инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

27 статьяның 3 өлешендә «,һәм Җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен раслау» сүзләреннән соң «инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет урамы, 6 йорт, Совет урамы, 8 йорт (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 йорт (клуб бинасы) адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Федотовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе В.И.Павлова